Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № X-5**

Балык Бистәсе штп. 2016 елның 23 апреле

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында

«Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8.1, 12.1 маддәләре, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 маддәсендәге 7.1 өлеше, «Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 558 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында»2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелә торганнарны расларга:

-«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары,

мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында Нигезләмә;

- "Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә вазыйфага керешкәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиеш булган муниципаль вазыйфалар исемлеге һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук бу муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә бурычлы вазыйфалары исемлеген раслау турында.

.2. «Балык Бистәсе муниципаль районы «муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында Нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2014 елның 12 ноябрендәге карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г.Вәлиев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
Х-5 номерлы карары белән
расланды

**«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру хакында**
**Нигезләмә**

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар һәм башка затлар чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы, «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указлары, «Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 558 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында»2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә әлеге Нигезләмә белән тәкъдим итү тәртибе билгеләнә:

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан, алар алган керемнәр, милек хокукындагы мөлкәт турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренеӊ) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар);

«Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан, керемнәре, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар).

2. Әлеге Нигезләмәдә каралган муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар дигәндә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы карары белән расланган исемлек нигезендә депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзалары, «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының сайланулы вазыйфаи затлары аңлашыла (алга таба шулай ук - «муниципаль берәмлек») (алга таба шулай ук – «район Советы»).

3. Әлеге Нигезләмә нигезендә «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыра, шулай ук «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыра, алар күрсәтелгән мәгълүматларны тапшыруның башка тәртибе һәм рәвешләре законнар белән билгеләнмәгән район Советы карары белән расланган исемлектә каралган.

4. Керемнәре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматлар муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе муниципаль вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар (алга таба - муниципаль вазыйфа биләүгә дәгъва кылучы граждан) тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча, вазыйфасы буенча вәкаләтләр бирелгәндә (вазыйфага билгеләгәндә) тапшырыла.

5. Район Советы карары белән расланган исемлектә каралган керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматлар «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә (алга таба - муниципаль вазыйфа биләүче зат) муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясенең керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган белешмә формасы буенча ел саен хисап елыннан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.тапшырыла.

6. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан вазыйфасы буенча вәкаләтләр биргәндә (вазыйфага билгеләнгәндә) түбәндәгеләрне тапшыра:

а) муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре (элекке эш урынындагы яисә сайланулы вазыйфаны биләү урынындагы керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматлар, шулай ук гражданның муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар;

б) гражданның муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында мәгълүматлар, шулай ук гражданның муниципаль вазыйфаны биләү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына (хисап датасына) милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар.

7. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат ел саен тапшыра:

а) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) барлык чыганаклардан алынган керемнәре (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматлар, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар;

б) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) алган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында мәгълүматлар; хисап чорында балигъ булган балалар өчен - балигъ булу яше җиткән дата буенча) барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп); шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукындагы мөлкәт һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар;

в) хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (туплау) капиталларында пайлар) сатып алу буенча һәр килешү буенча үзенең чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүматлар, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы хисап чорына кадәрге өч ел эчендә әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, һәм бу килешүләрне башкарган акча чыганаклары турында.

8. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук муниципаль вазыйфаны биләүче затның (район Советы депутатыннан тыш) керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлары район Советы вәкаләтле кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгеч) тапшырыла.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының тиешле авыл җирлеге Советы тарафыннан вәкаләтле кадрлар хезмәтенә (кадрлар эше буенча белгеч) район Советы депутаты тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлары тапшырыла.

9. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва итүче граждан яисә муниципаль вазыйфаны биләүче зат үзләре тәкъдим иткән мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүмат чагылдырылмаган яки тулысынча чагылмаган яки хаталы күрсәтелгән очракта, алар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә төгәлләштерелгән мәгълүматларны тапшырырга хокуклы.

Муниципаль вазыйфаны биләүче зат әлеге Нигезләмәнең 5 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән (аныкланган) мәгълүматларны тапшыра ала. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы граждан әлеге Нигезләмәнең 4 пункты нигезендә мәгълүматлар бирелгәннән соң бер ай эчендә аныкланган мәгълүматларны тапшыра ала.

10. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләргә дәгъва итүче гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан бирелгән мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

11. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан объектив сәбәпләр күрсәтелмәгән очракта, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар әлеге факт буенча каралырга тиеш:

а) район Советы депутатына карата:

районның законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясе тарафыннан;

муниципаль органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе (коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы күрсәтелгән органның вазыйфаи заты) тарафыннан район Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә даими комиссиясе йөкләмәсе буенча;

б) коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе (күрсәтелгән органның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты) тарафыннан район Советы, район Башлыгы йөкләмәсе буенча башка муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата.

12. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә тапшырыла торган мәгълүматлар конфиденциаль характердагы мәгълүматлар булып торалар, әгәр федераль закон белән алар дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматларга кертелмәгән булса.

Әлеге мәгълүматлар федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда вазыйфаи затларга бирелергә мөмкин.

13. Муниципаль вазыйфаны биләүче затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук җир кишәрлеге, башка күчемсез мөлкәт объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (тупланма) капиталлары катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган (килешү башкарылган) акчаларны алу чыганаклары турында мәгълүматлар, мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы хисап

чорына кадәрге соңгы өч елда муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, законнарда каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла: http:/ ribnaya-sloboda.tatarstan.ru., әлеге мәгълүмат булмаса, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында гаммәви мәгълүмат чараларына аларның гарызнамәләре буенча бастырып чыгару өчен тапшырыла.

14. Әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан әлеге Нигезләмә нигезендә район Советы тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар белән эшкә вәкаләтле кадрлар хезмәте затлары арасыннан муниципаль хезмәткәрләр, һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар бу мәгълүматларны фаш итүдә яисә законнарда каралмаган максатларда файдалануда гаепле, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүматларны таратуда гаепле затлар законнар нигезендә җаваплы булалар.

15. Әлеге Нигезләмә нигезендә муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан вазыйфа (вазыйфага билгеләнү) вәкаләтләре бирелгәндә тапшырылган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, шулай ук ел саен тапшырыла торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм әлеге мәгълүматларның дөреслеген тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат муниципаль вазыйфаны биләүче затның шәхси эшенә теркәлә (куела).

Әлеге Нигезләмә нигезендә үз керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар биргән граждан, муниципаль вазыйфа буенча вәкаләтләр бирелмәгән (күрсәтелгән вазыйфага билгеләнгән), бу мәгълүматлар аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла.

16. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белә торып ялган мәгълүматлар бирү (срогын бозып тапшыру белән) яисә тапшырылмаган очракта әлеге Нигезләмәнең 4 пунктында каралган муниципаль вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучы граждан һәм муниципаль вазыйфаны биләүче зат законнар нигезендә җаваплы булалар.

Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан үз чыгымнары турында тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматлар бирү яисә хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында тулы булмаган яки дөрес булмаган мәгълүматларны тапшыру яки бөтенләй тапшырмау очрагында, әгәр мондый мәгълүматларны тапшыру мәҗбүри икән, аны закон белән билгеләнгән тәртиптә биләгән вазыйфасыннан азат итүне таләп итә торган хокук бозу булып санала.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2016 елның 23 апрелендәге
X-5 номерлы карары белән
расланды

**Билгеләнгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле булган «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендәге муниципаль вазыйфалар исемлеге һәм бу муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы вазыйфалар исемлеге**

**1. Билгеләнгәндә гражданнар керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе.

**II. Әлеге муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар керемнәре, чыгымнаре, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшырырга тиешле «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар исемлеге**

Муниципаль берәмлек Башлыгы – муниципаль берәмлек Советы рәисе.

Муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары – муниципаль берәмлек Советы рәисе урынбасары.

Муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе.

Муниципаль берәмлек Советы депутатлары.